Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXXVI-4**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 13 апреле

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексына, Татарстан Республикасы Җир кодексы, "Татарстан Республикасы Җир кодексының 21 мадәсенә үзгәреш кертү турында" 2021 елның 27 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында төп эш урыны буенча эшләүче гражданнарга җир кишәрлекләрен түләүсез файдалануга бирү тәртибе турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2020 елның 6 октябрендәге II-6 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.2.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы составына керүче шәһәр яки авыл җирлекләрендә төп эш урыны буенча түбәндәге оешмалар төркемнәренең берсендә эшлиләр:

1) белем бирү оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: "педагогик белем бирү", "мәктәпкәчә белем бирү", "башлангыч сыйныфларда укыту", "өстәмә белем бирү педагогикасы";

2) медицина оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: "акушерлык эше", "акушерлык һәм гинекология", "анестезиология-реаниматология" "гериатрия", "йогышлы авырулар", "кардиология", "дәвалау эше", "неврология", "неонатология", "гомуми табиблык практикасы (гаилә медицинасы)", "онкология", "оториноларингология", "офтальмология", "педиатрия", "психиатрия", "рентгенология", "шәфкать туташы эше", "ашыгыч медицина ярдәме", "терапия", "фтизиатрия", "хирургия";

3) авыл хуҗалыгы оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: "агрономия", "ветеринария", "зоотехния", "агроинженерия", "авыл хуҗалыгын

механикалаштыру”;

4) мәдәният оешмаларында түбәндәге белгечлекләр буенча: “китапханә эше”, “китапханә-мәгълүмат эшчәнлеге”, “музеология һәм мәдәни һәм табигый мирас объектларын саклау”, “музыкаль белем бирү”, “халык сәнгате иҗаты”, “театральләштерелгән тамашалар һәм бәйрәмнәр режиссурасы”, “социаль-мәдәни эшчәнлек”, “хореография сәнгате”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы

Р.Р. Ислямов